ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 25.03.2024 405 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 841 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Бердәм бөтенроссия. спорт классификациясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 19 декабрендәге 1255 номерлы боерыгы нигезендә, Алабуга шәһәре прокуратурасының протестын карап чыгып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 841 номерлы карары белән расланган, спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2 бүлегенең 2.4.1 пунктындагы 2.4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Спорт разряды бирү өчен документларны карау вакыты теркәлгән көннән алып 16 эш көне тәшкил итә.

Спорт разрядын бирү яки бирүдән баш тарту турында Карар кабул итү спорт разрядын бирү өчен документларны карау тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә башкарыла. Спорт разрядын бирү турында карар оешма җитәкчесе имзалаган карар белән рәсмиләштерелә.».

1.2. 2.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) Россия Федерациясе гражданы паспортының икенче һәм өченче битләренең күчермәләре, шулай ук яшәү урыны турында белешмәләре булган битләрнең күчермәләре, ә ул булмаганда - Россия Федерациясе гражданы паспортының Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен раслаучы (таныклаучы),

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), документ биргән орган, документның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасы турында белешмәләрне үз эченә алган битләр күчермәләре.

Шәхесне таныклаучы документтан алынган мәгълүматлар, электрон формада тапшырганда, тиешле кырларга интерактив порталь формада кертелә
һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, соратуны юнәлтү юлы белән тикшерелә.

14 яшькә кадәргеләр өчен туу турында таныклык күчермәсе.

Әгәр туу турында таныклык чит телдә бирелгән булса, аның төп нөсхәсен һәм нотариаль яктан расланган тәрҗемәсен тәкъдим итә ала. Документларны электрон формада тапшырганда, нотариусның электрон-цифрлы имзасы белән расланган тәрҗемә бирелә.

Хәрби хезмәткә чакырылу буенча хәрби хезмәтне үтүче хәрбиләр, күрсәтелгән күчермәләр урынына Россия Федерациясе гражданы паспорты битләре хәрби билетның күчермәсен тәкъдим итә ала.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Лист согласования к документу № 405 от 25.03.2024
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 02.04.2024 10:57

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 02.04.2024 - 17:25 | - |